ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.12.2019 Казан шәһәре № 7-14/т

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар йөртүгә икътисадый нигезле тариф дәрәҗәсен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы һәм «Тимер юллардан ташу өлкәсендә табигый монополия субъектлары эшләренә (хезмәт күрсәтүләренә) карата тарифларны, җыемнарны һәм түләүне дәүләти җайга салу турында» 2009 елның 5 августындагы 643 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Тимер юллардан ташу өлкәсендә табигый монополия субъектлары эшләренә (хезмәт күрсәтүләренә) карата тарифларны, җыемнарны һәм түләүне билгеләү (үзгәртү) мәсьәләләрен карау тәртибен, шулай ук аларны билгеләү (үзгәртү) өчен тапшырыла торган документлар исемлеген раслау турында» 2011 елның 19 августындагы 506-Т номерлы боерыгы, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Шәһәр яны билгеләнешендә гомуми файдаланудагы тимер юл транспортында пассажирлар ташу өлкәсендә табигый монополия субъектларының хезмәт күрсәтүләренә икътисадый нигезләнгән тарифлар дәрәҗәсен формалаштырганда исәпкә алына торган икътисадый нигезләнгән чыгымнар дәрәҗәсен исәпләп чыгару методикасын раслау турында» 2017 елның 5 декабрендәге 1649/17 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар йөртүгә дистә километрлы бер зона өчен 27,53 сум күләмендә икътисадый нигезләнгән тариф дәрәҗәсе билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар йөртүгә икътисадый нигезләнгән тариф дәрәҗәсен билгеләү турында» 18.12.2018 № 7-11/т карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром